КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 май г.Казань № 367

Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турындагы нигезләмәсен һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составын раслау турында

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 10 өлеше, Махсус икътисадый зона белән идарә итү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыру турында 2016 елның 5 сентябрендәге С-582-АЦ/Д14 номерлы килешү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы белән идарә итү вәкаләтләрен башкару йөкләнгән орган итеп билгеләү турында» 2016 ел, 8 октябрь, 728 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу award карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турындагы нигезләмәсен һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 май, 367 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы (алга таба – Эксперт советы) вәкаләтләрен, Эксперт советы утырышларын үткәрү формасын һәм тәртибен билгели.

1.2. Бу Нигезләмәнең максатлары өчен төшенчәләр һәм терминнар «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) белән билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.3. Эксперт советы – күмәк орган һәм ул даими нигездә эшли.

1.4. Эксперт советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

## II. Эксперт советы вәкаләтләре

2.1. Эксперт советы:

а) Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы (алга таба – махсус икътисадый зона) резиденты статусын алырга ниятләүче затлар тарафыннан бирелгән бизнес-планнарны бәяләүне гамәлгә ашыра һәм бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре буенча бизнес-планга ярдәм күрсәтү турында йә бизнес-планга ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында карар (Федераль законның 13 статьясындагы 6 өлешенең 2 пунктында каралган очраклардан тыш) кабул итә;

б) махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга ниятләүче һәм Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген башкару турында килешү төзүгә заявка биргән затка бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яки берничә йөкләмәнең үтәлешен йөкләү турында карар кабул итә;

в) махсус икътисадый зона резидентының бизнес-планга үзгәреш кертүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү шартларына үзгәреш кертү хакында гариза белән мөрәҗәгате нигезендә бизнес-планга ярдәм күрсәтү турында йә бизнес-планга ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында, шулай ук әлеге резидентка

бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яки берничә йөкләмәнең үтәлешен йөкләү турында карар кабул итә;

г) махсус икътисадый зонада фәнни-техник продукция җитештерү турында карар кабул итә;

д) махсус икътисадый зонада сәнәгать-җитештерү һәм логистика эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында карар кабул итә.

## III. Эксперт советының составы һәм эшен оештыру

3.1. Эксперт советы составына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, кредит-финанс оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләре керергә мөмкин.

3.2. Эксперт советы Эксперт советы рәисе, Эксперт советы рәисе урынбасары, Эксперт советының җаваплы секретаре һәм Эксперт советы әгъзаларыннан тора. Эксперт советы әгъзаларының гомуми саны кимендә 7 һәм иң күбе 20 кешедән торырга тиеш.

3.3. Эксперт советы рәисе, Эксперт советы рәисе урынбасары, Эксперт советының җаваплы секретаре вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча туктатылырга мөмкин.

3.4. Эксперт советы утырышларына материаллар әзерләү өчен, Эксперт советы эшен оештыру һәм тәэмин итү өчен председатель тарафыннан эшче төркемнәр булдырылырга, аларның эшчәнлекләренә Эксперт советы әгъзалары белән беррәттән Эксперт советы составына кермәгән экспертлар да җәлеп ителергә мөмкин.

Эксперт советы утырышында Эксперт советы әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, әлеге утырыш хокуклы дип санала.

Эксперт советы утырышын Эксперт советы рәисе яисә, ул булмаган очракта, Эксперт советы рәисе урынбасары алып бара.

3.5. Эксперт советы карарлары кирәк булуга карап үткәрелә торган утырышларда Эксперт советы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Эксперт советы рәисенең яисә, ул булмаган очракта, Эксперт советы утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Эксперт советының һәр әгъзасы Эксперт советы утырышында үз фикерен әйтергә яки Эксперт советы утырышы беркетмәсендә чагылдырыла торган махсус фикерен язма рәвештә бирергә хокуклы.

Эксперт советы карарлары, турыдан-туры утырыш үткәрмичә, читтән торып тавыш бирү юлы (сораштыру юлы) белән кабул ителергә мөмкин. Бу Нигезләмә максатларында турыдан-туры утырыш үткәрүдә катнашу дигәндә Эксперт советы әгъзаларының утырыш үткәрелә торган урында фактта бергә булуы яки Эксперт советы әгъзаларының видеоконференцэлемтә йә Эксперт советының барлык әгъзаларына реаль вакыт режимында бер-берсен күрергә һәм ишетергә мөмкинлек бирә торган башка ысул ярдәмендә оештырылган утырыш үткәрү урынында бергәләп катнашуы аңлашыла.

Эксперт советының турыдан-туры утырыш үткәрүдә катнашу формасындагы

карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашкан Эксперт советының барлык әгъзалары тарафыннан имза куела һәм Эксперт советы рәисе тарафыннан раслана. Эксперт советының читтән торып тавыш бирү формасында (сораштыру юлы белән) утырышларын үткәрү йомгаклары беркетмәләренә Эксперт советының рәисе һәм җаваплы секретаре тарафыннан имза куела, бюллетеньнәр (сораштыру кәгазьләре) беркетмәгә тегелеп куела.

Эксперт советы карарлары техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявка һәм бизнес-планны алган көннән 40 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрелә.

3.6. Эксперт советының эш регламенты беренче утырышта Эксперт советы рәисе тарафыннан раслана һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кергән көннән 10 көн эчендә бастырып чыгару максаты белән техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә заявканы һәм бизнес-планны алган көннән 40 көн эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрелә.

3.7. Эксперт советы эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 май, 367 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы
составы

| | |
|---|---|
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Эксперт советы рәисе |
| Шакиров Динар Рәфикъ улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, Эксперт советы рәисе урынбасары |
| Вандюков Дмитрий Владимирович | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директорының дәүләт органнары белән хезмәттәшлек итү буенча урынбасары, Эксперт советының җаваплы секретаре (килешү буенча) |

Эксперт советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гыйсмәтов Радик Расыйх улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Дьячков Виктор Васильевич | «АйСиЭл – КПО ВС» акционерлык җәмгыятенең директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Зверков Владимир Игоревич | «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Новиков Анатолий Александрович | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Саматов Тимур Илгиз улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сапунов Игорь Валерьевич | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Святов Максим Александрович | Гражданлык җәмгыятен үстерү буенча президент грантлары буенча оператор фондының хокукый департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Семенихин Кирилл Владимирович | югары белем бирүче «Иннополис университеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Хәлимов Ренат Азат улы | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шагалиев Руслан Ринат улы | «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шакиров Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |